ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 гыйнвар, 2019 ел № 29/10

Урамга, шәһәр җәмәгать транспорты тукталышы пунктына исем бирү һәм шәһәр җәмәгать транспорты тукталышы пунктларының исемнәрен алыштыру турында

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең топонимика буенча комиссиясе тәкъдимен караганнан соң, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. 70А микрорайонында Нурми Шәрипов урамыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чигенә кадәр урамга, 1 нче кушымтадагы карта-схемада күрсәтелгән тәртиптә, «Завидная урамы» исемен бирергә.

2. Гостев урамы буенча «Эврика» мәдәни үзәге янындагы шәһәр җәмәгать транспорты тукталышына, 2 нче кушымтадагы карта-схемада күрсәтелгән тәртиптә, «Аэродромная» исемен бирергә.

3. Исемнәрен үзгәртергә:


1) шәһәр җәмәгать транспортының Автозавод проспекты буенча «Спортманеж» тукталышын, 3 нче кушымтдагы карта-схемада күрсәтелгән тәртиптә, «Цветочный бульвар» дип атарга;

2) шәһәр җәмәгать транспортының Муса Җәлил проспекты һәм Батенчук урамы буенча урнашкан «Студенческая урамы» тукталышын, 4 нче кушымтадагы карта-схемада күрсәтелгән тәртиптә, «Студенческая» дип атарга.

4. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев


Шәһәр Советының 2019 елның 24 гыйнварындагы 29/10 санлы Карарына
1 нче кушымта



Шәһәр Советының 2019 елның 24 гыйнварындагы 29/10 санлы Карарына
2 нче кушымта



Шәһәр Советының 2019 елның 24 гыйнварындагы 29/10 санлы Карарына
3 нче кушымта



Шәһәр Советының 2019 елның 24 гыйнварындагы 29/10 санлы Карарына 4 нче кушымта

